РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 март 2021 ел Кукмара ш. № 46

Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмә хакында

Гражданнар җәмгыятен үстерү принципларын гамәлгә ашырганда, шулай ук җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль органнар һәм оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда Иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән муниципаль район халкының ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алуга юнәлдерелгән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы турында нигезләмә хакында» 2008 елның 11 июлендәге 41 номерлы карары, «Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 14 июнендәге 29 номерлы, «Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Кукмара муниципаль районының 2016 елның 29 мартындагы 29 номерлы, «Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 22 мартындагы 204 номерлы карарлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев

Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 10 мартындагы 46 номерлы карарына кушымта

# КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы (алга таба – Иҗтимагый совет) иҗтимагый башлангычларда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы даими эшләүче киңәшмә һәм консультатив орган булып тора.

1.2. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, Кукмара муниципаль районы уставы, Кукмара муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәләренә таяна.

1.3. Иҗтимагый совет аның эшчәнлегендә Россия Федерациясе гражданнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар вәкилләре тарафыннан ирекле катнашу нигезендә төзелә.

1.4. Иҗтимагый Совет эшчәнлеге ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларында тормышка ашырыла.

## 2. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Иҗтимагый совет төзүнең максаты – гражданнар җәмгыятен үстерү принципларын гамәлгә ашырганда, шулай ук җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль органнар һәм оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыргандаИҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән муниципаль район халкының ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алуга юнәлдерелгән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.2. Иҗтимагый советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Кукмара муниципаль районы территориясендә эшләүче муниципаль программаларны гамәлгә ашыруга гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларны җәлеп итү;

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне карауда катнашу, Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль органнар һәм оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру;

- гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру.

## 3. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

3.1. Үзенә йөкләнгән бурычларны башкару өчен Иҗтимагый совет түбәндәгеләргә хокуклы:

- җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалардан, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль органнар һәм оешмалардан дәүләт серен һәм федераль законнар белән керү чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган мәгълүматтан тыш мәгълүмат соратып алырга;

- федераль һәм республика законнары нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашырырга;

- гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрергә;

- җирле үзидарә органнарына Кукмара муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча хокукый җайга салуны камилләштерү, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

- җирле үзидарә органнарына гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

- Иҗтимагый совет, комиссияләр һәм эшче төркемнәр утырышларына җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнар һәм оешмалар вәкилләрен чакырырга;

- Кукмара муниципаль районы (шәһәре) Советы утырышларында, шулай ук аның даими комиссияләре эшендә катнашырга;

- муниципаль район (шәһәр) халкына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирергә;

- муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турында җирле үзидарә органнары алдында үтенечнамә бирергә;

- Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

## 4. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ТӨЗҮНЕҢ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ВӘКАЛӘТЕ ВАКЫТЫ

4.1. Иҗтимагый Советта 15 кеше билгеләнә.

4.2. Иҗтимагый Совет әгъзаларының вәкаләтләре чоры 3 ел тәшкил итә һәм Иҗтимагый Советның беренче утырышы узган көннән исәпләнә. Иҗтимагый Советның яңа составтагы беренче утырышы узган көннән элекке составтагы Иҗтимагый Совет әгъзаларының вәкаләтләре туктатыла.

Иҗтимагый Совет әгъзаларының вәкаләтләре Иҗтимагый Совет тарафыннан үз-үзен таркату турында карар кабул ителгән очракта вакытыннан алда туктатыла. Әлеге карар Иҗтимагый Совет әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелек кимендә өчтән икесе тарафыннан Иҗтимагый Совет әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере инициативасы буенча кабул ителә.

4.3. Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар бер кандидатны күрсәтергә хокуклы.

4.4. Кукмара муниципаль районы Башлыгы Иҗтимагый совет әгъзаларының билгеләнгән саныннан кандидатларның яртысын тәкъдим итә.

Иҗтимагый совет Иҗтимагый совет әгъзаларының билгеләнгән саныннан кандидатларның яртысын тәкъдим итә.

Кукмара муниципаль районы Башлыгы Иҗтимагый совет әгъзаларының күрсәтелгән санын тәкъдим итмәгән очракта, Иҗтимагый совет составына кертү өчен документлар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң 10 көн узгач, кандидатларны тәкъдим итү хокукы Иҗтимагый советка күчә.

4.5. Иҗтимагый совет составын формалаштыру максатларында Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында Иҗтимагый совет составын формалаштыру процедурасын башлау турында хәбәрнамә урнаштырыла.

Хәбәрнамәдә Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатлар буенча тәкъдимнәр җибәрү вакыты һәм адресы күрсәтелергә тиеш. Тәкъдимнәрне кабул итү срогы хәбәрнамә урнаштырылган көннән алып 15 көннән ким һәм 30 көннән дә артык була алмый.

Хәбәрнамә Иҗтимагый совет әгъзаларының гамәлдәге составы вәкаләтләре тәмамлануга өч айдан да соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.

Күрсәтелгән срокта Иҗтимагый совет составына кандидатлар Кукмара муниципаль районы Башлыгына яисә Иҗтимагый советка түбәндәге документларны тапшыралар:

- Иҗтимагый советка кертү турында гариза-анкета;
- иҗтимагый берләшмәләрдән, коммерциягә карамаган оешмалардан яисә инициатив төркемнәрдән тәкъдимне раслый торган документлар (беркетмәләрдән) (иҗтимагый берләшмәләрдән, коммерциягә карамаган оешмалардан яисә инициатив төркемнәрдән тәкъдим ителгән очракта).

Кабул итүнең билгеләнгән чоры узганнан соң, Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатлар саны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан кимрәк булса, Кукмара муниципаль районы Башлыгы күрсәтелгән чорны Иҗтимагый Совет әгъзаларына өстәмә рәвештә тәкъдим кертү максатыннан озынайта, әмма ул 15 көннән дә артмый.

Документлар кабул итү тәмамланган көннән алып 30 көн эчендә Иҗтимагый Советны төзү процедурасы гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый Совет әгъзасына кандидат, Иҗтимагый Совет әгъзасы итеп расланганчы теләсә кайсы вакытта, Кукмара муниципаль районы Башлыгына язма гариза җибәреп, Иҗтимагый Совет әгъзасы булып раслауга ризалык бирү турындагы гаризасын кире алырга хокуклы. Бу очракта кандидат Иҗтимагый совет әгъзалыгына кандидатлар исемлегеннән төшереп калдырыла.

Иҗтимагый советның персональ составы Иҗтимагый совет төзү срогы тәмамланган көннән алып 10 көн эчендә Кукмара муниципаль районы Башлыгы карары белән төзелә һәм раслана.

Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 3 көн эчендә Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

4.6. Иҗтимагый совет әгъзаларына кандидатлар күрсәтү түбәндәгеләргә рөхсәт ителми:

1) сәяси партияләр, аларның региональ һәм җирле бүлекләре тарафыннан;

2) «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә экстремистик эшчәнлекне гамәлгә ашыруны булдырмау турында язма рәвештә кисәтү чыгарылган иҗтимагый берләшмәләр, коммерциягә карамаган башка оешмалар - суд тарафыннан законсыз дип танылмаган булса, кисәтү чыгарылганнан соң бер ел дәвамында;

3) әгәр туктатып тору турындагы карар суд тарафыннан законсыз дип танылмаган булса, эшчәнлеге Федераль закон нигезендә туктатып торылган иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар.

## 5. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ӘГЪЗАСЫНЫҢ СТАТУСЫ, ХОКУКЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

5.1. Кукмара муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданины Иҗтимагый совет әгъзасы булырга мөмкин.

5.2. Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар:

1) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

2) кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;

3) ике гражданлыгы булган затлар;

4) дәүләт хакимияте органнарында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары.

5.3. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет, аның комиссияләре һәм эшче төркемнәре эшендә шәхсән үзләре катнаша. Карарлар кабул иткәндә

тавыш бирү хокукын Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыру рөхсәт ителми.

5.4. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Иҗтимагый совет, Иҗтимагый совет комиссияләре һәм эшче төркемнәре эшчәнлегенең теләсә кайсы мәсьәләсе буенча үз фикерләрен иркле әйтергә;

2) Иҗтимагый совет эше турында мәгълүмат булган документларны, башка материалларны алырга;

3) Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибе буенча тәкъдимнәр кертергә, аларның утырышларына материаллар әзерләүдә, Иҗтимагый совет карарлары проектларын әзерләүдә, утырышларның көн тәртибе мәсьәләләре буенча фикер алышуда катнашырга;

4) Иҗтимагый совет карары белән килешмәгән очракта, бу фикер әйтелгәнне телдән һәм язмача белдерергә, ул Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсендә билгеләнә һәм карарга кушып бирелә;

5) Иҗтимагый совет карарларын гамәлгә ашыруда катнашырга.

5.5. Иҗтимагый совет әгъзалары үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда аларны күрсәткән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның карарлары белән бәйле булырга тиеш түгел.

5.6. Иҗтимагый совет әгъзасы үз эшчәнлеген Иҗтимагый советта сәяси партияләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар, шулай ук шәхси мәнфәгатьләрдә файдаланырга хокуксыз.

5.7. Иҗтимагый совет әгъзасын үзен күрсәткән иҗтимагый берләшмә һәм коммерциягә карамаган оешма тарафыннан кире алырга рөхсәт ителми.

5.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) аның вәкаләтләре чоры тәмамланса, шулай ук Иҗтимагый Совет үз-үзен таркату турында карар кабул иткән очракта;

2) Иҗтимагый Совет составыннан чыгу турында аның тарафыннан гариза бирү;

3) аны хокукый сәләтсез дип тану;

4) аның үлеме;

5) аңа карата чыгарылган судның гаепләү карары законлы көченә керү;

6) аның Этика Кодексы нормаларын бозуы – Иҗтимагый палата утырышында кабул ителгән Иҗтимагый совет әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә яртысы карары буенча;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату йә ике гражданлык булдыру;

8) Иҗтимагый совет утырышлары эшендә җитди сәбәпләрсез систематик (өч тапкырдан артык) катнашмау;

9) Кукмара муниципаль районыннан читкә даими яшәү урынына чыгу.

Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында карар Иҗтимагый совет утырышында кабул ителә һәм Иҗтимагый совет карары белән рәсмиләштерелә, анда Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату датасы күрсәтелә.

5.9. Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан имзаланган Иҗтимагый совет әгъзасы таныклыгына ия. Иҗтимагый совет рәисе таныклыгын Кукмара муниципаль районы Башлыгы имзалый.

Таныклыкның үрнәге һәм тасвирламасы Кукмара муниципаль районы Башлыгы күрсәтмәсе белән раслана.

## 6. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ЭШЛӘРЕН ОЕШТЫРУ

6.1. Яңа составлы Иҗтимагый совет үзенең беренче утырышына Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча җыела.

Иҗтимагый советның беренче утырышы Иҗтимагый совет инициативасы буенча чакырыла.

6.2. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла.

6.3. Иҗтимагый совет карарлары Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

6.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү характерында.

Җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль органнар һәм оешмалар аларга юнәлдерелгән карарларны, җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларын карыйлар һәм, аларны алган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча, ә кичектерү түзмәслек очракларда – кичекмәстән Иҗтимагый советка нигезле җаваплар җибәрә.

6.5. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышларында раслана торган планнар нигезендә оештыра.

Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.6. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп формалары – Иҗтимагый совет утырышлары, аеруча мөһим проблемалар буенча тыңлаулар һәм «түгәрәк өстәлләр», муниципаль район халкыннан сораштырулар, форумнар, семинарлар һәм эшчәнлекнең законнарга каршы килми торган башка формалары.

6.7. Иҗтимагый советның чираттан тыш утырышы Иҗтимагый совет Рәисе карары буенча яисә Иҗтимагый совет әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бере инициативасы буенча чакырылырга мөмкин.

6.8. Иҗтимагый совет утырышы, әгәр анда Иҗтимагый советның билгеләнгән санының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

6.9. Иҗтимагый совет эшендә Кукмара муниципаль районы Башлыгы һәм аның урынбасарлары, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм аның урынбасарлары, Кукмара муниципаль районы Советы депутатлары, җирле үзидарә органнарының башка вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты хезмәткәрләре катнаша ала.

6.10. Иҗтимагый совет әгъзалары үзләре составыннан Иҗтимагый совет рәисен ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән сайлыйлар.

Иҗтимагый совет рәисе:

1) Иҗтимагый советның чираттагы утырышы көн тәртибе проектын төзи һәм аны уздыру датасын билгели;

2) Иҗтимагый совет әгъзаларына чираттагы яисә чираттан тыш утырыш уздыру турында хәбәр итә;

3) Иҗтимагый совет эшчәнлеге мәсьәләләре буенча соратулар җибәрә;

4) аеруча мөһим мәсьәләләр буенча комиссияләрнең һәм эшче төркемнәрнең тыңлауларын, утырышларын уздыру турында карар кабул итә;

5) Иҗтимагый совет әгъзалары Этикасы кодексын эшли һәм Иҗтимагый совет раславына тәкъдим итә;

6) үз эшчәнлеге турында Иҗтимагый советка хисап тапшыра;

7) Иҗтимагый совет карары буенча башка вәкаләтләрне үти.

Иҗтимагый совет Рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Иҗтимагый совет Рәисе карары буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының берсе башкара.

6.11. Иҗтимагый совет әгъзалары үзләре составыннан Иҗтимагый совет секретарен ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән сайлыйлар.

Иҗтимагый совет секретаре:

1) Иҗтимагый совет, комиссияләр, эшче төркемнәр утырышларының көн тәртибе проектларын һәм аларның утырышлары беркетмәләре проектларын әзерли;

2) Иҗтимагый советның агымдагы эшчәнлеген оештыра;

3) Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышының вакыты, урыны һәм көн тәртибе, шулай ук Иҗтимагый совет эшенең расланган планнары турында хәбәр итә;

4) Иҗтимагый советның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча Иҗтимагый совет утырышларына мәгълүмат-аналитика материаллары әзерләүне җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә тәэмин итә;

5) Иҗтимагый совет Рәисе кушуы буенча үз компетенциясе чикләрендә башка мәсьәләләрне хәл итә.

Иҗтимагый совет секретаре булмаган очракта, аның вазыйфаларын Иҗтимагый совет Рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының берсе башкара.

6.12. Иҗтимагый совет карарлары бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр, шулай ук аның эшчәнлегенең оештыру һәм башка мәсьәләләре буенча карарлар формасында кабул ителә.

Иҗтимагый совет бәяләмәләре, тәкъдимнәре һәм мөрәҗәгатьләре рекомендация характерында һәм ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Иҗтимагый советның оештыру һәм аның эшчәнлегенең башка мәсьәләләре буенча карарлары Иҗтимагый совет әгъзалары өчен мәҗбүри характерга ия һәм, әгәр әлеге Нигезләмәдә башкасы каралмаган булса, ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, Иҗтимагый совет рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

6.13. Иҗтимагый совет гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләләре буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрергә хокуклы.

Иҗтимагый экспертиза нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләре рекомендация характерында була һәм җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

6.14. Иҗтимагый совет законнар нигезендә гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның гражданнар инициативалары турында мәгълүмат җыя һәм эшкәртә.

Иҗтимагый совет иҗтимагый тормышның актуаль мәсьәләләре буенча гражданнар форумнары, тыңлаулар һәм башка чаралар оештыра һәм үткәрә.

Иҗтимагый совет гражданнар һәм иҗтимагый берләшмәләр, гражданнарның башка берләшмәләре игътибарына белдерелгән граждан инициативалары турында мәгълүмат җиткерә.

6.15. Иҗтимагый совет муниципаль район территориясендә граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында ел саен доклад әзерли.

Иҗтимагый Советның еллык доклады җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына җибәрелә.

Иҗтимагый советның еллык доклады Кукмара муниципаль районы Советы утырышында тыңлана.

Иҗтимагый Советның еллык докладындагы тәкъдимнәр җирле үзидарә органнары эшендә кулланылырга мөмкин.

6.16. Иҗтимагый совет юридик зат түгел.

## 7. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ, МУНИЦИПАЛЬ ОЕШМАЛАР, ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННАР НИГЕЗЕНДӘ АЕРЫМ ГАВАМИ ВӘКАЛӘТЛӘРНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ БАШКА ОРГАННАР ҺӘМ ОЕШМАЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ҖӘМӘГАТЬ КОНТРОЛЕН ҮТКӘРГӘНДӘ ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

7.1. Иҗтимагый совет «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган формада һәм тәртиптә җәмәгать контролен гамәлгә ашыра.

7.2. Иҗтимагый Советы җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны оештыручы, инициатор буларак чыгыш ясарга, шулай ук уздырыла торган чараларда катнашырга;

2) Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль оешмалардан, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнарыннан һәм оешмаларыннан җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган мәгълүматтан тыш, федераль законнар нигезендә файдалануы чикләнгән шәхси белешмәләр һәм мәгълүмат турында белешмәләр соратып алырга;

3) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган очракларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларга, Кукмара муниципаль

районының федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнарына һәм оешмаларына йөрергә;

4) җәмәгать контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча йомгаклау документын әзерләргә һәм аны җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Кукмара муниципаль районының башка органнарына һәм оешмаларына һәм массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрергә;

5) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары ачыкланган очракта җәмәгать контролен гамәлгә ашыру барышында алынган материалларны федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә һәм прокуратура органнарына җибәрергә;

6) федераль законнарда каралган очракларда билгесез затларның хокукларын яклау, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен судка мөрәҗәгать итәргә;

7) Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган башка хокуклардан файдаланырга.

7.3. Җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда Иҗтимагый совет түбәндәгеләргә бурычлы:

1) җәмәгать контроле турында Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә;

2) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә бәйле федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

3) Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль оешмалардан, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка органнарыннан һәм оешмаларының законлы эшчәнлегенә каршылыклар булдырмау;

4) әгәр аларны тарату федераль законнар белән чикләнгән булса, җәмәгать контролен гамәлгә ашыру барышында алынган мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга;

5) «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру буенча үз эшчәнлеге һәм контроль нәтиҗәләре турында мәгълүматны халыкка игълан итәргә;

6) федераль һәм республика законнарында каралган башка бурычларны үтәргә.

## 8. ЙОМГАКЛАУ ҺӘМ КҮЧМӘ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

8.1. Иҗтимагый Советның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 13.

8.2. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү Кукмара муниципаль районы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.3. Әлеге Нигезләмә рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.